ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОТАРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОТАРКА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Октябрьская, д.17, с. Отарка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422180

Октябрь ур., 17 нче йорт, Отарка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422180

тел.(факс): (85563) 3-74-77; e-mail: Otar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

“22 ” декабрь 2017 ел — № 33

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Отарка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә чүп, үләннәр, яфрак һәм башка калдыкларны, материалларны яки әйберләрне яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге № 69-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 20 сентябрендәге № 947 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Мамадыш районы прокурорының 2017 елның 10 августындагы № 02-01-18-2017 санлы Отарка авыл җирлеге территориясендәге торак пунктларның янгынга каршы тотрыклылыгын арттыру максатларында Янгын куркынычсызлыгы турындагы законнарны үзгәртү турындагы мәгълүматы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Отарка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктларының гомуми файдаланудагы җирләрендә чүп-чар, үлән, яфракны һәм башка калдыкларны, материалларны яки әйберләрне яндыруны тыярга, җилсез һавада, чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны, материаллар яки эшләнмәләрне яндыруны даими контрольдә тоту шартларында якындагы корылмаларга кадәр кимендә 50 метр ераклыкта урнашкан урыннардан тыш.

2. Чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыклар, материаллар яки әйберләрне яндыручы түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

- Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге төр эш башкарылуы турында хәбәр итәргә (1 нче кушымта);
- янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен төгәл үтәп, үзен беренчел чаралар белән тәэмин итәргә, янгын сүндерү чараларына һәм янгын сүндерү системасына чакыру өчен мобиль чарага ия булырга;

- эшләр тәмамланганнан соң чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны, материалларны яки эшләнмәләрне яндыру урыннарын чистартырга, янмый торган материалны каты коммуналь калдыклар җыю урынына чыгарырга.
3. Әлеге карар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Отарка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус янгынга каршы режим кертелгән чорда гамәлдә булмый.
4. Әлеге карар нигезләмәләре «Атмосфера һавасын саклау турында» 04.05.1999 ел, №96-ФЗ Федераль закон һәм «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында»24.06.1998 ел, №89-ФЗ Федераль закон белән яндыру тыелган калдыкларга, материалларга һәм эшләнмәләргә карата үз гамәлләрен таратмый.
5. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче /Х.М.Минникаев/

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башкарма комитетының 22.12.2017 ел, № 16 карарына 1 нче кушымта

Кемгә:

_______________________________________
(оешма җитәкчесенең Ф.И.О.)

адрес:

_____________________________________

кемнән:___________________________
(Ф.И.О.)

_____________________________________

адрес:

___________________________________,

телефон: ____________, факс: _
электрон почта адресы: ________________

N ______________________
"___"_________ ____ ел.

ХӘБӘРНАМӘ

РФ Хөкүмәтенең "Янгынга каршы режим турында" 25.04.2012 ел, № 390 карары ("Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләре"белән бергә)нигезендә,сезгә "___"_________ ____ ел, _____ сәгатьтән _____ сәгатькә кадәр

_____________________________________________________________________________________
_____
(чүп, калдыклар, материаллар яки әйберләр төре)
_____________________________________________________________________________________
____ калдыклар яндыру турында хәбәр итәм.

Чүп-чар, калдыклар, материаллар яки продуктларны яндыру урыны ________________________

_____________________________________________________________________________________.

Янган урынга чүп-чар, калдыклар, материаллар яки әйберләр китерү ысулы _____________________________________________________________________________________
____.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Отарка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә чүп, үләннәр, яфрак һәм башка калдыкларны, материалларны яки әйберләрне яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында ___ _____________ 2017 ел, №_____ карары белән таныштым.

________________ ________________/_______________
(дата) (имза) (Ф.И.О.)